Социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмаларның ресурс үзәкләре коммерцияле булмаган оешмаларга ярдәм күрсәтү инфраструктурасын формалаштыру элементы булып тора. Хәзерге вакытта социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмаларга ярдәм күрсәтүче 2 ресурс үзәге үз эшчәнлеген гамәлгә ашыра:

«Горизонт» социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмаларның Ресурслар үзәге» автономияле коммерцияле булмаган оешмасы (Яр Чаллы шәһәре), Социаль өлкәдәге инновацияләр үзәге (Казан шәһәре).

«Горизонт» Ресурслар үзәгенең төп максатлары:

- социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмаларның, территориаль иҗтимагый үзидарәләрнең, иҗтимагый советларның, гражданлык җәмгыятенең, социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмаларның максатчан төркемнәре белән эшләүнең инновацион юнәлешләрен кертү һәм үз һөнәри компетенцияләрен даими камилләштерү юлы белән үз эшчәнлекләрендә югары нәтиҗәләргә ирешү омтылышы белән берләштерелгән башка институтларның тотрыклы берләшмәсен булдыру һәм үстерү.

Эшчәнлек төрләре:

– Яр Чаллы шәһәре һәм Кама аръягының социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмалары өчен консультация хезмәтләре;

– коммерцияле булмаган оешмалар эшчәнлеген проектлаштыру һәм аларны тормышка ашыруда булышлык күрсәтү;

– коммерцияле булмаган оешмалар өчен тренинглар, семинарлар, мастер-класслар үткәрү;

– социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмаларга ярдәм күрсәтүгә юнәлдерелгән проектларны тормышка ашыру;

– социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмаларның социаль хезмәтләрен стандартлаштыру;

– хокук өлкәсендәге хезмәтләр;

– бухгалтерлык исәбе һәм аудит өлкәсендәге хезмәтләр;

– авыр тормыш хәлендә калган, халыкның социаль якланмаган катламнары, шул исәптән балалар, яшүсмерләр, сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән затлар, ятим балалар, балалар һәм гаиләләр һәм өлкән буын кешеләренең хокукларын, мәнфәгатьләрен яклауга юнәлдерелгән гомумшәһәр, төбәк һәм федераль социаль әһәмиятле программаларны

эшләүдә һәм аларны тормышка ашыруда булышлык күрсәтүдә катнашу. Элемтәләр: т. 8-960-067-39-61; irina-komadorova@yandex.ru

Социаль өлкәдәге инновацияләр үзәге (Казан) социаль эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтүнең гамәлдә булган төрләрен камилләштерүгә һәм Татарстан Республикасы территориясендә социаль проблемаларны хәл итүгә, республика дәрәҗәсендә социаль хезмәтләрнең сыйфатын үстерүгә ярдәм күрсәтүгә, социаль өлкәдә эшләүче оешмаларның нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлдерелгән чаралар системасын булдыруга юнәлдерелгән.

Социаль өлкәдәге инновацияләр үзәгенең максатлары:

- Татарстан Республикасы территориясендә социаль эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү һәм аны үстерү;

- социаль өлкәдә перспективалы һәм стратегик проектларны һәм инновацияләрне популярлаштыру һәм нәтиҗәле төстә алга чыгару;

- социаль проектларга һәм инициативаларга ярдәм күрсәтүнең сыйфатлы яңа дәрәҗәсен тәэмин итү;

- әлеге өлкәдә закон чыгару инициативалары һәм закон проектлары проблемаларын ачыклау һәм фикер алышу максатында Татарстан Республикасы социаль эшмәкәрләре өчен нәтиҗәле дискуссия мәйданчыгы булдыру.

Социаль өлкәдәге инновацияләр үзәгенең төп бурычлары:

- социаль эшмәкәрлек нигезләренә һәм үз социаль бизнесыңны ачуның практик күнекмәләренә өйрәтү;

- Россия һәм чит илләрнең уңышлы социаль-эшмәкәрлек практикаларын тарату, җәелдерү;

- социаль эшмәкәрләр эшчәнлегенә консультация, мәгълүмати һәм аналитик ярдәм күрсәтү;

- социаль эшмәкәрлеккә, ресурс ярдәменең барлык төрләрен дә кертеп, ярдәм күрсәтүнең барлык юлларын да булдыру һәм үстерү. Элемтәләр: т. 8(843) 296-08-85; ciss.rt.ru